СОВЕТ ТУБЫЛГЫТАУСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул.Молодежная, д.73,
с. Тубылгы Тау,423181

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТУБЫЛГЫТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Яшьләр урамы, 73
Тубылгы Тау авылы,423181

тел.: (8-84348) 3-82-58, факс: (8-84348) 3-82-44, Tub.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2021 елның 31 нче мае № 11-33

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советы 21.01.2002 елның 7-18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советының 21.01.20021 елның 7-18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 нче статьяда:

1 өлешнең 9 пунктында «җирлекнең тиешле вәкиллекле органы депутаты буларак, аның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату йә» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 нче өлешнең 12 нче пунктын «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса» сүзләрен өстәргә;

5 нче өлештә «йә авыл җирлеге депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 16 нчы статьяда:

1 өлешнең беренче абзацында «этика» сүзләреннән соң «җирлек Советы тарафыннан раслана торган документлар,» сүзләрен өстәргә;

2 өлештә «тиешле комиссия» сүзләрен «җирлек Советы карары белән төзелә торган депутат этикасы кагыйдәләрен үтәү буенча комиссия» сүзләренә алмаштырырга;

3) 17 нче статьяның 1 нче өлешендәге беренче абзацта «җирлек» сүзләреннән соң түбәндәге сүзләр өстәргә:

«үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы комитет,»;

4) 19 нчы статьяның 1 нче һәм 2 нче өлешләрендә «органнар» сүзләрен «комиссияләр» сүзләренә алмаштырырга;

5) 21 нче статьяда «кабул итәргә» сүзләрен «кабул итә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырылырга тиеш - http://pravo.tatrstan.ru, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында - http://novosheshminsk.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф. Исмагилов